СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**26 март, 2024 ел** **№ 397**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Биектау муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә класслы чиннар бирү һәм саклап калу тәртибе турындагы, Биектау муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең квалификация имтиханын тапшыру һәм аларның белемнәрен, күнекмәләрен һәм осталыкларын (һөнәри дәрәҗәсен) бәяләү тәртибе хакындагы нигезләмәләрне раслау турында» 2014 елның 31 мартындагы 352 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы прокуратурасының 2024 елның 2 февралендәге 02-08-01 номерлы протесты нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2014 елның 31 мартындагы 352 номерлы карары белән расланган Биектау муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләренә класслы чиннар бирү һәм саклап калу тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Класслы чин бирелү көне дип класслы чин бирелү турында карар кабул итү көне санала.»;

1.2. 22 пунктны үз көчен югалткан дип таныргa;

1.3. 24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24. Муниципаль хезмәткәргә класслы чин бирү турындагы карар, 18 пунктта күрсәтелгән очраклардан тыш, барлык кирәкле документлары булган класслы чин бирү турындагы күрсәтмә җирле үзидарәнең класслы чиннар

бирергә вәкаләтле органына яисә вазыйфаи затына кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф. Хисамутдинов